Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение Муслюмовский лицей
Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан

# *История лицея*
# *Лицей тарихы*

1930нчы елда төзелгән агач мәктәп ихатасы янәшәсендә 1986нчы елда 624 урынлы ике катлы яңа мәктәп калкып чыга. Нибары 7 ай эчендә сафка баса ул.

Яңа мәктәпкә, гәрчә ул 1986нчы елның август аенда төзелеп беткән мәктәпләр исемлегендә булса да (җылыту системасы, байтак кына эчке эшләр тәмамланмаган иде), 1987нче елның 12 гыйнваренда гына укый башлыйлар. Мәктәпне ачу тантанасында КПСС райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары Ә. Әхмәтгалиев, район мәгариф бүлеге мөдире М. Йосыпов һәм “Авыл утлары” гәзитеннән бер хәбәрче катнаша.

Иске мәктәптәге укучылар икегә бүленә. 6 – 10нчы сыйныфлар яңа мәктәпкә күчә, иске мәктәптә башлангыч класслар кала. Ике мәктәптә дә укулар 2 сменада була. Башлангыч мәктәпнең директоры итеп рус теле һәм әдәбияты укытучысы Руфия Кирам кызы Мусина, ә аның укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасары итеп рус тле һәм әдәбияты укытучысы Венера Кашап кызы Хайруллина билгеләнә. Озак та үтми, мәктәп директоры вазифалары Венера Кашап кызына тапшырыла. Иске мәктәп 1996нчы елда кабаттан мөстәкыйль 2 нче урта мәктәп дип йөртелә башлый.

Мәктәп директоры Мөҗәһит Әхмәтҗанов истәлекләреннән:

“...Яңа мәктәп төзелүнең тарихы болайрак булды. 1985нче елның гыйнвар ае иде. Бик кызып, мәгариф эшләре буенча республика семинарына әзерләнеп ятабыз (ә ул семинар безнең мәктәптә үтәргә тиеш). Районыбызга кинәт кенә КПСС өлкә комитетының идеология секретаре Рәис Кыям улы Беляев килеп төште. Безнең мәктәпкә дә керде. 50нче елгы янгын нәтиҗәсендә купшакланып беткән кызыл кирпичле мәктәп стенасына карап торды да бик гаҗәпләнде. “Үз гомеремдә мондый мәктәпне күргәнем юк иде. Хәзер төрмәләрне дә моннан яхшырак итеп төзиләр. Ат өркерлек бит бу...” – диде. Кунакны мастерскойга алып кердек. Анда стена агартып яткан укытучыларга күз салды да:

– Кемнәр бу? – дип сорады.

– Укытучылар, семинарга әзерләнәбез бит, – дидем.

– Нинди семинарга?

– Республика семинарына...

– Бернинди дә семинар да булмаячак! – дип кырт кисте Рәис Кыям улы. – Шушындый мәктәптә семинар үткәрү кемнең башына килде икән? – дип, түшәмне терәткән бизәкле баганага таянып, хәтсез генә башын селкеп торды. Машиноведение кабинетына кермәде. Үтешли, ярым җиргә сеңгән ашханәне күрсәттек. Башын гына селкеде. “Үзем Чаллыда эшләгәндә мөрәҗәгать итсәгез, бер дигән мәктәп салдырып биргән булыр идем. Мәктәбегез йөрәгемә уелып калды”, – диде (Рәис Кыямович Чаллы гиганты төзелгән дәвердә КПССның шәһәр комитеты 1нче секретаре булып эшләгән иде).

Мәктәпнең проект-смета документлары барлыгы, ләкин планга гына кертеп булмавы, ике сменалы һәм салкын мәктәптә укытуның авырлыгы, укучылар белән өстәмә эшләргә мөмкинлекләр юклыгы турында зарландык. Ул үзенең дә укытучылар гаиләсеннән булуын, безнең хәлләр аның өчен яттүгеллеген белдерде. Шундый дәрәҗәле урында эшләп тә, гади булып калган җитәкчегә исебез китеп карап тордык.

Көндезге сәгать бердә райкомда сөт буенча зур киңәшмә үткәрелде. Семинарның булмаячагын, яңа мәктәпнең бер ел эчендә төзелеп бетәчәген белдерде КПСС өлкә комитеты секретаре. Колакларыбызга ышанмадык. Күз алдыбызга китерә алмадык. Шулай да, документацияләре күтәреп, Түбән Кама, Бөгелмә, Казан юлларын таптый башладык.

1986 нчы елның август аена мәктәбебез, нигездә, төзелеп тә бетте. Аны “Главтатнефтегазстрой”ның 5нче тресты (җитәкчесе – К.З. Чепик) башкарып чыкты. Азнакай белән Мөслим арасында СМУ-29 төзүчеләре бихисап мәртәбәләр ураганнардыр... Вак-төяк эшләрне тәмамлаганчы, байтак гомер үтте.

Яңа мәктәп башта үзәк котельныйдан җылытылды. Ләкин мәктәп җылынмады. Мәктәп котельныеның проект-смета документациясен төзетү өчен Казанга йөрергә, газ ягарга рөхсәтне Мәскәүгә, РСФСР Мәгариф министрлыгына барып алырга туры килде.

1985нче елның 6 нчы июнендә Татарстан районнарының мәгариф бүлеге мөдирләре катнашында республика семинары барыбер безнең Мөслимдә булды. Семинарда катнашучылар Мөслим урта мәктәбен, “Селхозтехника” район берләшмәсендәге мәктәп кабинетларын карадылар. 7нче июньдә исә мәгариф хезмәткәрләре Яңа Усы-Күбәк урта мәктәбе, – Күбәк сөтчелек фермасы – ПМК-13. Урожай” колхозы – Тат. Бүләр урта мәктәпләре маршруты буенча йөрделәр. Семинар күпләрнең күңеленә хуш килде..